*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2023-2024 нче уку елы)
**5 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 60 минут**
**Максималь балл – 32**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Парсыз яңгырау тартык авазны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) [б]
   ә) [х]
   б) [ң]
   в) [ғ]

2. Хәреф белән аваз саны туры килмәгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) алъяпкыч
   ә) тиен
   б) читлек
   в) яшь

3. Сүз басымы дөрес куелган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) чәйнекләрне′
   ә) чәйнеклә′рне
   б) чәйне′кләрне
   в) чә′йнекләрне

4. *Кыска* сүзенең антонимын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) тар
   ә) биек
   б) озын
   в) зур

5. Ясалма фигыльне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) тыңла
   ә) уйла
   б) сөйлә
   в) яса

6. Урын-вакыт килешендәге исемне билгеләгез. **(2 балл)**

а) авылга
ә) авылдан
б) авылның
в) авылда

7. Сыйфатны билгеләгез. **(2 балл)**

а) тишек
ә) алар
б) төче
в) укый

8. Сорау җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**

а) Кошлар җылы якка очып киттеләр.
ә) Кошлар ник җылы якка очып китәләр?
б) Сез кошларга җимлекләр элегез.
в) Күгәрченнәр безнең якларда кышлыйлар.

## II. Теоретик бирем.

Төшеп калган сүзләрне языгыз. **(5 балл)**

[к] – ____________ тартык аваз. [ү] – ____________ нечкә сузык аваз. Күп мәгънәле сүзләрнең туры һәм ____________ мәгънәләре була. Сыйфатларның ____________ дәрәҗәсе *-рак/-рәк* кушымчасы өстәлеп ясала. *Без, сез, алар* – ____________ алмашлыклары.

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Текстны татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(5 балл)**

*Наступил сентябрь. Стоят тёплые деньки. Листья берёзы жёлтые, золотистые. На полянах краснеет рябина. Ели стоят зелёными.*

2. Быелгы көз нинди? Шул хакта 6 җөмлә төзеп языгыз. **(6 балл)**